КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 12 декабрь г.Казань № 1117

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карар белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карар белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 11 февраль, 105 нче; 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче; 2015 ел, 19 март, 165 нче; 2017 ел, 26 май, 307 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Тәртипнең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Ташламалы шартларда юлламалар белән «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» 2001 елның 15 декабрендәге 166-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә пенсия билгеләнгән, бүтән нигезләр буенча пенсия алучы яки «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы беренче өлеш нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәч эшләгән (хезмәт иткән) өчен гомерлек акча алучы, Татарстан Республикасы

территориясендә даими яшәүче, гаиләсенең җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасы буенча халыкның җан башына яшәү минимумы күләменең 400 процентыннан артмаган (Россия Федерациясенең норматив хокук актлары нигезендә халыкның шифаханә-курорт дәвалавына хокуклы категорияләренә кергән гражданнардан тыш), Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Авыруларны шифаханә-курорт дәвалавына медицина сайлап алуы һәм җибәрүе тәртибе турында» 2004 ел, 22 ноябрь, 256 нчы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Амбулатор шатларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында кулланыла торган медицина документларының унификацияләнгән формаларын һәм аларны тутыру тәртипләрен раслау турында» 2014 ел, 15 декабрь, 834н номерлы боерыгы белән расланган 070/у номерлы форма буенча бирелгән белешмә (алга таба – 070/у номерлы форма буенча шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен белешмә, гражданнар) белән расланган шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗлык турында медицина күрсәткечләре булган шартларда пенсионерлар тәэмин ителә.

Әлеге Тәртип 2001 елның 15 декабренә «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» 2001 елның 15 декабрендәге 166-ФЗ номерлы федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, гаиләсенең җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасы буенча халыкның җан башына яшәү минимумы күләменең 400 процентыннан артмаган, 070/у номерлы форма буенча шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен белешмә белән расланган шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗлык турында медицина күрсәткечләре булган гражданнарга тарала.»;

Тәртипнең 2 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Шифаханә-курорт дәвалавына юллама сорап мөрәҗәгать итү тәртибе

2.1. Шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗ граждан шәхесне таныклаучы документын күрсәтеп, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының граждан даими яшәгән урын буенча территориаль социаль яклау органына (алга таба – территориаль социаль яклау органы), түбәндәге документларны теркәп, әлеге Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча гариза белән мөрәҗәгать итә:

070/у номерлы форма буенча шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен белешмә;

Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турында белешмәләрдән тыш, Тәртинең 1.3 пунктында күрсәтелгән тәртиптә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган гариза биргән айга кадәрге өч айда гаиләнең һәр әгъзасы керемен раслый торган документлар.

2.2. Территориаль социаль яклау органы:

2.2.1. Ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати багланышлар системасыннан файдаланып электрон формада шифаханә-

курорт дәвалавына юллама алуга гражданны исәпкә кую турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны ала:

вәкаләтле оешмадан «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» 2001 елның 15 декабрендәге 166-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә пенсия билгеләнү турында һәм 2018 елның 31 декабренә гражданның әлеге федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүе хакында мәгълүматлар;

вәкаләтле оешмалардан гариза бирүченең гаилә составы турында мәгълүмат;

Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәре турында мәгълүмат;

Граждан территориаль социаль яклау органына гариза белән бергә әлеге пунктның икенче – дүртенче абзацларында күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны үз теләге белән кертергә хокуклы.

2.2.2. Барлык кирәкле документлар белән бергә гариза керткән көннән алып 10 көн эчендә гражданны юллама алу өчен исәпкә кую яки куюдан баш тарту турында карар кабул итә һәм тиешле карарны гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр белән, «Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында шәхси кабинет аша) гражданга җиткерә;

2.2.3. Гражданның шәхси эшенә тапшырылган документларны һәм юллама алу өчен аны исәпкә кую турында карарны теркәп, аны формалаштыра;

2.2.4. Гариза тапшыру көненә карап, шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗ гражданнар исемлекләрен төзи.

2.3. Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләр:

Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларның тулы пакетын тапшырмау;

Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны гамәлдә булу вакыты чыккан килеш тапшыру.

2.4. Граждан гаиләсенең җан башына уртача кеременең Татарстан Республикасында билгеләнгән пенсионерның яшәү минимумының 400 проценты зурлыгыннан артып китүе гражданны юллама алу өчен исәпкә куюдан баш тарту өчен нигез булып тора.

2.5. Граждан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә җавап тота.»;

Тәртипнең 3.1 пунктындагы өченче абзацта «Нигезләмәнең» сүзен «Тәртипнең» сүзенә алмаштырырга;

Тәртипнең 3.2 пунктында «Ак Барс» акционерлар коммерция банкы» ачык акционерлар җәмгыятенең район филиалларында» сүзләрен «кредит оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең 3.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Алынган юлламадан баш тартылган очракта граждан урнашу башланганга кадәр эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә аны территориаль социаль яклау органына кире кайтарырга тиеш, граждан шифаханә-курорт дәвалавына алынган юлламадан файдалана алмауның гафу итәрлек сәбәпләреннән тыш. Гафу итәрлек

сәбәпләр граждан объектив рәвештә юлламадан баш тарту өчен нигез булып торган шартлар килеп чыгуны раслый торган документлар белән раслана. Әлеге абзацта каралган бурычны гафу итәрлек сәбәпләрсез билгеләнгән вакытта үтәмәгәндә граждан үзенең юллама алуга хокукын тормышка ашырган дип санала.

Граждан юлламадан баш тарткан очракта баш тарту факты территориаль социаль яклау органы тарафыннан язмача теркәлә, юллама бер эш көне эчендә республиканың тиешле муниципаль районда яки шәһәр округында исәпкә кую датасы буенча авыруның тиешле профиле булган икенче кешегә бирелә (070/у номерлы форма буенча шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен белешмә нигезендә).»;

Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин